**Республика Татарстан**
**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы,
ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» декабрь, 2019 ел № 2031

Татарстан Республикасы Питрәч
муниципаль районы Башкарма комитетының
2019 елның 11 октябрендәге 1587 номерлы
карарына һәм «Питрәч коммуналь челтәрләре»
муниципаль унитар предприятиесе уставына
үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законның 9, 12, 13 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 1999 елның 11 октябрендәге 1587 номерлы карарының 7 пунктына үзгәреш кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. «Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесенең исәп-хисап счетына акча күчерү юлы белән теркәлгәннән соң 3 ай эчендә 600 000 (алты йөз мең) сум күләмендә устав фондын формалаштырырга.

2. «Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе уставына (алга таба – Устав) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1. Уставның 1 бүлегендәге 1.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Предприятиенең устав фонды - 600 000 (алты йөз мең) сум.»

2.2. 3.3. уставның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Предприятиенең Питрәч муниципаль районы бюджеты хисабына 600 000 (алты йөз мең) сум күләмендә устав фонды бар.»

3. «Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе җитәкчесе Кәбиров Фәрит Хамат улына Уставка үзгәрешләр кертү буенча дәүләт теркәве буенча вакытында мөрәҗәгать итәргә кирәк.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

А. В. Хәбибуллин